**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге составына керүче Красный Баран авылы торак пунктында

**16 декабрь 2021 е.** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге составына керүче Красный Баран авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Зур Полянка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган 1 төркем инвалидлардан, уку студентларыннан, гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 700 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:

- җирлек эчендәге юлларга вак таш җәю, төзекләндерү һәм карап тоту (шартнамә буенча хезмәт өчен түләү, сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу);
- техниканы - тракторны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);
- авыл җирлегенең торак пунктында урамнарны яктыртуны карап тоту (урам фонарьларын, исәпкә алу приборларын, СИП үткәргечен сатып алу, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);
- су астына төшүче насос сатып алу, янгынга каршы гидрантлар сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Зур Полянка авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Полянка авыл җирлеге Красный Баран АМЙ бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Красный Баран авылы, Үзәк ур., 48Б йорт.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы** **М.Р. Афанасьева**